**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3124**
**19.06.2019**

Шосседа велоспорт буенча Татарстан Республикасы ачык чемпионатын һәм беренчелеген үткәрү көннәрендә Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында

Шосседа велоспорт буенча Татарстан Республикасы ачык чемпионаты һәм беренчелеге үткәрелү уңаеннан, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юллар эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ санлы Федераль законның 30 маддәсе, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ санлы Законының 27 маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 нче карары белән расланган Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яки вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибе, шәһәр Уставының 41 маддәсе 9 пунктының 24.1 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. 2019 елның 20 июлендә 11.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында Хәсән Туфан проспекты буенча бер юнәлештә Сөембикә проспектыннан Җиңүнең 40 еллыгы урамына кадәр транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә.

2. 2019 елның 21 июлендә 11.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә:

1) Металлургическая урамы буенча Техническая урамы белән кисешкән урыннан Моторная урамына кадәрге автомобиль юлы участогында;

2) Моторная урамы буенча Металлургическая урамы белән кисешкән урыннан Промышленная урамына кадәрге автомобиль юлы участогында.

3. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең ЮХИДИ бүлегенә транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында гражданнар иминлеген, җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәтен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

4. Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка җиткерергә һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә:

1) әлеге карарны «Интернет» челтәрендә ведомствоның рәсми сайтында урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына җибәрергә;

2) автомобиль юлларын ябу өчен кирәкле йөк транспорты бирүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин